Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге составына керүче Шомбыт авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

28 ноябрь 2022 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шомбыт авыл җирлеге составына керүче Шомбыт авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шомбыт авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау һәм кышкы карап тоту;
- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын карап тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу, су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү);
- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка, Кызыл Яр торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу, территорияләрне җыештыру, коймалар төзү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбытавыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт;Шомбыт авылы, Завод урамы, 22ж йорт; Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Сергеев Н.Е.

Шомбыт авыл җирлеге башлыгы Сергеев Н.Е.